**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.07.2021 № 723

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 18.01.2019 ел, 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актларны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Белем бирү оешмаларының муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 18.01.2019 ел, 30 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9.2 пунктының 1 пунктчасының 6 абзацын, 9 бүлегендәге 9.4 пунктының 1 пунктчасының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «е) федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, белем бирү стандартлары һәм мөстәкыйль билгеләнә торган таләпләр турында (алар булганда);»;

7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7.3. Оешма укырга керүче һәм (яки) аның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) үзенең уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен лицензия бирү датасы һәм теркәү номеры турындагы белешмәләр, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаучы белем бирү программалары һәм башка документлар, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга тиеш»;

Административ регламентның 9.4 пунктындагы 2 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе итеп йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин